| | | |
|---|---|---|
| **Каралган** | **Килешенгән** | **Раслыйм** |
| МБ житәкчесе | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУнең УТЭБДУ | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБББМУнең директоры |
| _______ /Калинина М.Б./ | _______ / Сәгъдиева Г.Ф./ | _______ / Әхмәтшина Л.М./ |
| беркетмә № 1 | | Приказ № 92 |
| «20» август 2013ел. | «20» август 2013 ел. | «28» август 2013 ел. |

уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы

«Яңа Мәлкән ТГБМ» ГББМУ

Калинина Мәкфия Биктимер кызы, 1 категорияле укытучы

уку, 1 нче сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган.
беркетмә № 1
« 20 » август 2013 ел.

2013 – 2014 нче уку елы

## Әдәби укудан эш программасы

**Әдәби укудан эш программасы түбәндәгеләргә нигезләнеп төзелде:**

- яңа федераль белем бирүнең дәүләт стандартлары
- "Башлангыч гомуми белем бирү программалары"(Татар телендә гомуми белем бирү мәктәбе өчен.1-4сыйныфлар,2010 ел)

**УМК.**

▪ "Башлангыч гомуми белем бирү программалары"(Татар телендә гомуми белем бирү мәктәбе өчен.1-4сыйныфлар,2010 ел)

▪"Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек",(Әлифба), 2011 ел ,авторлары:

И.Х.Мияссарова,Ф.Ш.Гарифуллина,Р.Р.Шәмсетдинова; (дәреслекләрнең региональ исемлеге)

▪"Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек",(Әдәби уку),

2011 ел,авторлары:Г.М.Сафиуллина,М.Я.Гарифуллина,Ә.Г.Мөхәммәтҗанова,Ф.Ф.Хәсәнова (дәреслекләрнең региональ исемлеге)

### Әдәби уку

Матур әдәбият әсәрләре яшь буынның күңелен, хисләрен баетуда, аларның тирә-яктагы тормышны һәм кешеләрне аңлый башлавында. Нәрсәнең яхшы һәм матур, ямьсез һәм начар булуын төшенүдә, зәвыгын тәрбияләүдә, туган халкының рухи дөньясы белән азыкландуында бик тә үтемле, көчле тәэсир итүче нигез булып тора. Чөнки әдәбият – сүз сәнгате. Аның шушы зур мөмкинлекләрен тиешенчә файдалану – әдәбият укытуның төп **максаты.**

Башлангыч сыйныфларда укучы татар балалары өчен төзелгән әдәби укудан эш программасы түбәндәге **бурычларны** үз эченә ала:

- татар әдәбияты, аның аеруча күренекле вәкилләре турында беренчел күзаллау булдыру;
- әдәби әсәрне тыңлап һәм укып аңлау күнекмәләре булдыру;
- текст белән танышу, эчтәлеген сөйләп бирү күнекмәләрен формалаштыру, аны камилләштерә бару;
- әдәби текстларны дөрес, тиз һәм тора-бара сәнгатьле итеп укуларына ирешү;
- мөстәкыйль рәвештә әдәби әсәрләрне укырга һәм үзләштерергә күнектерү, белемгә омтылыш, китапка карата кызыксыну тәрбияләү;
- татар әдәбияты белән бергә башка халыкларның сүз сәнгатенә дә кызыксыну тәрбияләү;
- укучыларның мантыйклы һәм иҗади фикер йөртүен, затлы зәвыгын үстерү;
- әдәби әсәрләр ярдәмендә үз-үзеңне әдәпле тотуга ихтыяҗ тәрбияләү;
- дөрес, бәйләнешле итеп телдән һәм язма сөйләмгә өйрәтү һәм башкалар.

### "Әдәби уку" курсына характеристика

**1 нче сыйныфта "Әдәби уку" курсы грамотага өйрәтү чорыннан соң башлана**.

Уку һәм сөйләм үстерү татар халык авыз иҗаты әсәрләре, татар язучыларының әсәрләрен өйрәнүне күз алдында тота. Эш программасы әдәби жанрларны (бишек җырлары, санамышлар, әйтем, мәкаль, табышмак, әкият, мәсәл, хикәя, шигырь һ. б.) өйрәнүне бурыч итеп куя.

Эш программасында китап белән танышу төрле төрдәге мәгълүмат һәм библиографик белем формалаштыру чыганагы буларак карала.

Сөйләм һәм китап уку эшчәнлеге төрләре барлык сөйләм, китап уку эшчәнлеген һәм төрле төрдәге текстлар белән эшләүне, ягъни укучыларның сөйләм әдәбен формалаштыруны, коммуникатив күнекмәләрне камилләштерүне күз алдында тота.

Ел дәвамында уку күнекмәләрен үзләштерү үзгәрә: башта сүзләрне һәм сүзтезмәләрне тулысынча уку үзләштерелә, аннан соң җөмләдәге сүзләрне интонацион куку алымнары формалаша, йөгерек уку арта, ел ахырында эчтән уку кертелә башлый. Укучылар әзлекле рәвештә рациональ уку һәм укыганның эчтәлеген аңлап укуның орфоэпик һәм интонацион нормаларын, төрле уку төрләрен үзләштерәләр һәм аларны билгеле бер сөйләм мәсьәләсен чишкәндә кулланалар.

Укырга өйрәтү белән бергә, сөйләм үстерүне камилләштерү бара. Әңгәмәдәшнең сөйләгәнен яки укыганын тыңлап зиһенгә алу, сөйләмне аңлау, укылган яки тыңланылган әсәр буенча сорау бирү, аңа карата үз фикереңне белдерә белү күнекмәләре камилләштерелә. Диалог формалары һәм сөйләм этикеты үрнәкләре үзләштерелә.

Укучыларның монологик сөйләме камилләшә, актив сүзлек запасы байый.

Укучылар текстны тулысынча һәм кыскартып сөйләргә өйрәнәләр.

Әдәби уку дәресләрендә текстлар турында беренчел күзаллау үстерелә, укучылар әдәби, фәнни-популяр мәкалә, публицистик язмаларны аерырга, текст исемен эчтәлеге белән чагыштырырга, текстларны өлешләргә бүләргә, текстка исем куярга, план төзергә, төп һәм өстәмә мәгълүматны аера белергә өйрәнәләр.

Әдәби әсәрләрне анализлау нәтиҗәсендә, геройларның сөйләмнәре, кылган гамәлләре, характерлары турында фикер йөртәләр, аларга характеристика бирәләр, геройның үз-үзен тотышына бәя бирәләр, мораль нормалар белән чагыштыралар.

**Әдәби уку предметының уку планындагы урыны**

Башлангыч гомуми белем бирү программасы әдәби укуга 2 дәрес исәбеннән төзелгән. Уку елының дәвамлылыгы 33 атна. Грамотага өйрәтү чоры атнага 2 сәгать исәбеннән (21 атна) ел буена 42 сәгать укытыла. Әдәби уку дәресләре “Яңа Мәлкән төп мәктәбе” ГББУнең уку – укыту планы буенча атнага 2 сәгать исәбеннән (12 атна) ел буена 24 сәгать укытыла.

**Шәхси үсеш-үзгәреш, предметара һәм предмет нәтиҗәләре**

Әдәби уку буенча төзелгән эш программасы башлангыч сыйныф укучыларының шәхси үсеш-үзгәреш, предметара һәм предмет нәтиҗәләрен үзләштерүне күздә тота.

**Шәхси үсеш-үзгәреш нәтиҗәләренә ирешү осталыгы булып түбәндегеләр санала:**

-гомуми кулланыш нормалары һәм кыйммәтләре күзлегеннән кешеләрнең эш- гамәлләрен, тормыш ситуацияләрен бәяләү;

-текстны “эмоциональ кичерү”, үз фикереңне белдерү;

-башка кешеләрнең хисләрен аңлау,кешенең хәленә керү, аңа теләктәшлек белдерү;

-укылган әсәр геройларына карата үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;

**Предметара нәтиҗәләр** булып әдәби уку курсын өйрәнгәндә универсаль уку гамәлләре формалашу санала.

| **Шәхси универсаль уку гамәлләре.** | **Регулятив универсаль уку гамәлләре.** | **Танып-белү универсаль уку гамәлләре.** | **Коммуникатив универсаль уку гамәлләре.** |
|---|---|---|---|
| 1.Түбәндәге кыйммәтләрне аңлый һәм бәяли белү: яхшылык, түземлелек, табигать, туган ил, гаилә һ.б. Үз гаиләңә, туганнарыңа, ата-анаңа хөрмәт.<br>2.Укучы ролен үзләштерү. Укуга карата кызыксыну формалаштыру.<br>3. Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен | 1.Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оештыру.<br>2.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.<br>3.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү | 1.Китап белән эшләү: бирелгән бүлекне өйрәнгәндә формалашучы белем-күнекмәләрне билгеләү.<br>2.Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу.<br>3.Геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын табу. | 1.Дәрестә һәм тормыш ситуацияләрендә диалогта катнашу.<br>2.Укытучы, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү.<br>3.Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшү, хушлашу,рәхмәт белдерү.<br>4.Башкаларның сөйләмен тыңлап аңлау.<br>5. Парлап һәм күмәк эшләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| тотышларын бәяләү. | планын билгеләү. | 4.Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү. | |

**Регулятив универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып – продуктив уку технологиясе ; **танып-белү универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып-дәреслектәге текстлар, беренчел мәгълүмат белән эшләү күнекмәләрен тәэмин итүче методик аппарат;**коммуникатив универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып продуктив уку технологиясе һәм эшне парлап, кечкенә төркемнәрдә оештыру хезмәт итә.

**Предмет нәтиҗәләре:**
-укытучы, укучы укыган текстны ишетеп аңлау;
-бөтен сүзләрне аңлап, дөрес уку;
-текстны тулысынча сөйләү;
-кечкенә күләмле шигырьләрне ятлау;
-рәсем буенча телдән хикәя төзү;
-автор,текст исеме һәм текстның эчтәлеген билгеләү;
-хикәя , шигырьне аера белү.

**Уку материалының эчтәлеге**

***Әзерлек чоры (2 сәг.)***

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчедән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү.

Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау.

Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу.

***Әлифба чоры (38 сәг.)***

**Сузык авазлар**. Сузык [а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө] авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.

Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.

Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.

**Парсыз сонор тартык авазлар**:[м, н, л, р, й, ң] сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе : үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки тоткарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр.

Калын һәм нечкә яңгырашлы сүзләрдә сонор тартык авазлар әйтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хәрефләре (а, у, о, ы) белән (ма, му), нечкә яңгырашын нечкә сузык аваз хәрефләре (ә, и, ө, ү, э) белән белдерү. Сүздә һәр авазны аерып әйтү алымы. Рәсем һәм схема белән бирелгән

сүзләргә аваз анализы. Анализлана торган сүз составына кергән аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү.

Чагыштыру өчен бирелгән сүзләрдәге (мал-мәл) авазларның аермалы билгеләренең мәгънә функциясенә ия булуын билгеләү.

Сонор авазларны белдерүче басма баш һәм юл хәрефләрнең формаларын үзләштерү. Ябык иҗекләрне (ай) һәм калын һәм нечкә яңгырашлы кушылмаларны (ма, мә, му, мү һ.б.), шулай ук парсыз тартык авазлар уртада һәм ахырда булган сүзләрне (май, малай) уку. Сүзләрне иҗекләп уку белән чагыштырып, орфоэпик уку һәм әйтү алымы.

**Сүз башында һәм сүз уртасында |й] авазы**:Я, е, ю хәрефләренең ике авазга [йа], [йә], [йы], [йә], [йу], [йү] билге булып килүләре: яра, ял, юл, куян, баян.

Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку. Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз формасын график формага күчерү процессын күзәтү.

Я, е, ю хәрефләрен куллану кагыйдәләрен үзләштерү. Бу хәрефләр кергән сүзләрне һәм иҗекләрне уку. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.

**Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар:**Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү: нечкәлек яңгырау, саңгырау ([д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ] һ.б.) парларның үзара мөнәсәбәтен ачыклау. Мәсәлән бар-бар, бар-пар һ.б. Өйрәнү тәртибендә басма хәреф формаларын үзләштерү.

Авазларында аерма булган сүзләрне, яңгырау һәм саңгырау тартык авазлардан башланган сүзләрне әйтеп карау, чагыштыру күнегүләре (бар-пар).

Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку.

Башлангыч сүзне һәм сүзнең авазын алмаштыру яки аваз өстәү юлы белән ясалган яңа сүзләрне (бур-бура-буран), шулай ук ике яктан да бертөрле укыла торган (ана) сүзләрне уку. Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.

Аваз. иҗек.сүз.җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру.

А**еру билгеләре булып торган ь һәм ъ тан соң [й] авазы**:Язуда аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ һәм сузык аваз хәрефләре ярдәмендә [й] авазының язуда бирелешен (ь+е,я, ю; ъ+е, ю, я) аңлату. (Я, е, ю хәрефләре алдындагы иҗек калын сүзләргә (алъяпкыч) ъ билгесе, алдагы иҗек нечкә сүзләргә (дөнья) ь билгесе куелуын аңлатыла).

Аеру билгеләре һәм сузык аваз хәрефләре белән белдерелгән [й] авазлы сүзләрнең аваз анализы. [Й] авазы кергән сүзләрнең аваз схемасын уку. аны хәреф формасына үзгәртү, соңыннан башта иҗекләп, аннан соң орфоэпик дөрес итеп уку.

ь, ъ билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү.

(Бу билгеләрнең [гъ], [къ] авазларының калынлыгын белдерү өчен дә кулланылуын аңлату (игътибар, тәкъдим). Калын[гъ] һәм [къ] авазлары булган сүзләрнең калынлыгын белдерү өчен язуда калын сузык аваз хәрефләре куланылуын, әйткәндә, иҗек нечкәлеген белдерү өчен, ахырдан ь билгесе куелуын ассызыклан үтәргә кирәк. Мәсәлән мәкаль сүзендә[къ] калын кече тел тартыгы, аның калынлыгын белдерү өчен к дан соң а язабыз, укыганда [мәкъәл] дип укыйбыз, икенче иҗекне нечкә итеп уку өчен сүз ахырына ь билгесе куябыз.)

**Парсыз тарлык авазлар**:Парсыз [х, һ, щ, ц] тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергән иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.

***Әлифбадан соңгы чор ( 2 сәг.)***

Төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен формалаштыру. Текстагы «авыр» (озын һәм таныш булмаган) сүзләрне укыганда иҗекләп укырга мөмкин. Җөмләнең тыныш билгеләренә карап җөмләләр арасында тукталыш (пауза) ясау. Хикәяләү, сорау, тойгылы җөмләләрнең интонациясен бирү. Укылган текст буенча бирелгән сорауларга тулы җавап бирү. сайлап алып эчтәлеген сөйләү, текстның башын, ахырын үзгәртү, аңа яңа исем бирә белү күнекмәләренә ия булу.

Текстның

1) башлам (вакыйга нәрсәдән башлана).

2) төп өлеш (катнашучы-геройлар белән нәрсә була),

3) йомгаклауга(нәрсә ничек тәгәлләнә) туры килә торган кисәкләрен табу һәм уку. Текста сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү

Шигырь һәм проза. Шигъри һәм чәчмә әсәрләр турында гомуми кузаллау булдыру. Әдәби әсәрнең исеме, авторы (язучы, шагыйрь), халык авыз иҗатында билгесезлек (авторы юк).

**Программаны тормышка ашыру өчен кулланыла:**

*Мияссарова И.Х, Гарифуллина Ф.Ш., Шәмсетдинова Р.Р* “Әлифба” Казан. “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты. 2011.
*Мияссарова И.Х, Гарифуллина Ф.Ш., Шәмсетдинова Р.Р* “Әлифба. 1 нче язу дәфтәре”, “Әлифба. 2 нче язу дәфтәре” Казан. “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты. 2013.
*Мияссарова И.Х, Гарифуллина Ф.Ш., Шәмсетдинова Р.Р* “Әлифба. Методик кулланма” Казан. “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты. 2011.
*Мияссарова И.Х, Гарифуллина Ф.Ш., Шәмсетдинова Р.Р* “Грамотага өйрәтү программасы: уку һәм язу” Казан. «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты. 2011.
*Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х.* Әдәби уку:1нче сыйныф: дәреслек. Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2012.
*Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х.* Әдәби уку: мөстәкыйль эш дәфтәре. Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2012.
*Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х.* Әдәби уку:1нче сыйныф: укытучы өчен методик кулланма. Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2012.

**Укытуны материаль-техник һәм мәгълүмати яктан тәэмин итү**

«Әдәби уку» предметын өйрәткәндә, балаларның матур әдәбият һәм халык авыз иҗаты белән кызыксынуларын, иҗади сәләтләрен, мөстәкыйль фикерләү, фикерләрен дәлилли алу осталыгын үстерү һәм тирәнтен өйрәтү максатыннан, түбәндәге материаль-техник чараларны файдалану мөмкинлеге күздә тотыла:

- халык авыз иҗаты үрнәкләре;
- тарихи чыганаклар;
- сынлы сәнгать әсәрләре;
- тема буенча музыкаль әсәрләр;
- күрсәтмә әсбаплар;
- мультимедиа укыту программалары;
- электрон дәреслекләр;
- Интернет материаллары;
- электрон китапханә;
- компьютер программалары;
- укучыларның белемнәрен тикшерү программалары;
- сүзлекләр;
- белешмә материаллар;
- татарча сайтлар;
- балалар өчен чыгарылган газета һәм журналлар;
- яңа әдәби китаплар;
- аудио-һәм видеоәсбаплар;
- интерактив тикшерү программалары;
- лингафон кабинеты.

**Педагогик технологияләр һәм укыту чаралары:**

1.Традицион технологияләр:
- иллюстратив-күрсәтү технологиясе (Я.А. Коменский)

2. Педагогик процесста шәхси- ориентлашкан якын килүгә нигезләнгән технологияләр:
-Хезмәттәшлек педагогикасы (С.Т. Шацкий, В.А.Сухомлинский, К.Д. Ушинский, Ж.Ж. Руссо, Я. Корчак );
- Ш.А. Амонашвилиның шәхескә мәрхәмәт белән карау нигезенә корылган технологиясе .
3.Укучылар эшчәнлеген активлаштыруга юнәлтелгән педагогик технологияләр:
-Уен технологиясе.
4. Үстерешле укыту технологиияләре:
-Ә.З.Рәхимовның үстерешле укыту технологиясе.
5.Проект технологиясе.
6.Компьютер технологиясе.
7.Укыту чаралары:
электрон
басма
техник чаралар

***Календарь - тематик план***

**Сыйныф:** *1*
**Укытучы:** *Калинина Мәкфия Биктимир кызы*
**Беренче яртыеллыкта:** *32 сәг.,* **икенче яртыеллыкта**: *34 сәг.*
**Барысы:** *66 сәг.*; **атнага:** *2 сәг.*

**Календарь-тематик план** · *"Башлангыч гомуми белем бирү программалары"(Татар телендә гомуми белем бирү мәктәбе өчен.1-4сыйныфлар,2010 ел) , Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе "Яңа Мәлкән төп белем бирү мәктәбе"нең 2013-2014 нче уку елына укыту планына*

**нигезләнеп төзелде.**

**Дәреслекләр:**

*1. Мияссарова И.Х, Гарифуллина Ф.Ш., Шәмсетдинова Р.Р* ***"Әлифба"*** *Казан. "Мәгариф-Вакыт" нәшрияты. 2011*

*2. Гарифуллина Ф.Ш., Мияссарова И.Х.* ***Әдәби уку:1нче сыйныф****: дәреслек. Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшрияты, 2012.*

| № п /п | Дәрес темасы | Сәг. саны | Дәрес тибы | Укыту эшчәнлеге төрләре | Планлаштырган материалны үзләштерү нәтиҗәләре | | Контроль төре | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Көтелгән нәтиҗәләр | Күпкырлы уку эшчәнлеге(УУД) | | План буенча | фактта |
| 1. | **<u>1.Әзерлек чоры дәресләре</u>** (4 сәг)<br><br>Сөйләм. "Өч кыз"әкияте. | 1 | яңа материалны өйрәнү | Басма һәм язма хәрефләре булган рәсемле алфавит танышу | Кешеләрнең әйтеп һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллый белергә | **Личностные УУД(** шәхес буларак) әхлакый-этик бәяләү<br>**Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Планлаштыру<br>Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | Көндәлек тикшерү | 2.09 | 2.09 |
| 2 | "Куян кызы" әкияте. Җөмлә. Сүз. | 1 | Катнаш дәрес | бәйләнешле сөйләмне үстерү өчен тематик картиналар белән эш | Әйтеп һәм язып сөйләшүләрне гомуми күзаллау | **Личностные УУД(** шәхес буларак) Үзбилгеләм ә(самоопределение)<br>Укуның дәлилләре(мотивация учения)<br>Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности личности). | Фронталь тикшерү | 5.09 | 5.09 |
| 3 | "Яшелчә бакчасы", "Алма бак-часы".<br>Текст. | 1 | Катнаш дәрес | кушылмалар схемасы белән эшләү | сүзләргә аера белергә, сүзләрне иҗек һәм авазларга тарката белергә | **Познавательные УУД** (танып-белү) Гомуми уку (общеучебные)<br>- танып-белү максатын билгеләү;<br>-кирәкле информация туплау;<br>- билге-символлар<br>- модельләштерү | Сораулар буенча әңгәмә | 9.09 | 9.09 |
| 4 | "Көз","Зи-рәк чәүкә",<br>Текст.Җөм-лә. | 1 | яңа материалны өйрәнү | абак, сузыклар таблицасы белән эш | сүзләрне иҗек һәм авазларга тарката белергә | **Познавательные УУД** (танып-белү) Логик<br>- билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>- җитмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау;<br>- чагыштыру,объектларны классларга бүлү, серияләү өчен критерийлар сайлау; | Фронталь тикшерү | 12.09 | 12.09 |
| 5 | **<u>2.Әлифба чоры (40сәг.)</u>**<br>Сузык **[а]** авазы | 1 | катнаш | Басма һәм язма хәрефләре булган рәсемле | Сузык а А авазларны әйтеп һәм ишетеп карап | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең | Фронталь тикшерү | 16.09 | 16.09 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм А,а хәрефләре. Алма бакчасында. | | | алфавит | аера белергә ; | эзлеклелеге<br>Прогнозлау(алдан фаразлау | | | |
| 6 | Сузык [ә] авазы һәм Ә, ә хә-рефләре. Гаилә. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | Нечкә сузыкларны, авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Личностные УУД(** шәхес буларак) Мәгънә төзелеше (Смыслообразования)<br>«минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», һәм шул сорауга җавап бирә белү. социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү(оценивание усваиваемого содержания, исходя из социальных и личностных ценностей, обеспечивающее личностный моральный выбор) | Фронталь тикшерү | 19.09 | 19.09 |
| 7 | Сузык [ы] авазы һәм ы, Ы хә-рефләре. Су спорты. | 1 | катнаш | бәйләнешле сөйләмне устерү өчен тематик картиналар белән эш | Сузык авазларны-калын, нечкә сузыкларны аеру | | Фронталь тикшерү | 23.09 | 23.09 |
| 8 | Сузык **[Э]** авазы, Э, э (е)хәрефләре. | 1 | катнаш | Басма һәм язма хәрефләре булган рәсемле алфавит | Сузык авазларны-калын, нечкә сузыкларны аеру | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Иптәшеңенең үз-үзен тотышы белән идарә итү,,фикерне әйтә белү<br>**Познавательные УУД** (танып-белү) Логик<br>- билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>- җитмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау;<br>- чагыштыру,объектларны классларга бүлү, сериялəү өчен критерийлар сайлау; | Фронталь тикшерү | 26.09 | 26.09 |
| 9 | Сузык [и] авазы һәм И,и хәрефләре. | 1 | яңа материалны өйрәнү | бәйләнешле сөйләмне устерү өчен тематик картиналар белән эш | авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | | | 30.09 | 30.09 |
| 10 | Сузык **[у]** авазы һәм У, у хәрефләре. Учак. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | Сузык Уу авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) төшенчәләрне билгеләү,нәтиҗәләрне чыгару;<br>- сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачыклау,<br>- логик фикерләү чылбырын төзү, | Фронталь тикшерү | 3/10 | 3/10 |
| 11 | Сузык[о] авазы һәм О,о хәрефләре. | 1 | катнаш | кушылмалар схемасы белән эш | Сузык авазларны, әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Сораулар куелышы<br>Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек | Сораулар буенча әңгәмә | 7/10 | 7/10 |
| 12 | Сузык**[ө]** авазы | 1 | катнаш | Басма һәм язма | Сузык авазларны | **Личностные УУД(** шәхес буларак) | Сораулар | 10/10 | 10/10 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм Ө,ө хәрефләре. | | | хәрефләре булган рәсемле алфавит белән эш | әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | Үзбилгеләнә ә(самоопределение)<br>Укуның дәлилләре(мотивация учения)<br>Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности личности). | буенча әңгәмә | | |
| 13 | Белемнәрне ныгыту.Өй-рәнгән хә-рефләрне кабатлау. | 1 | катнаш | бәйләнешле сөйләмне устерү өчен тематик картиналар белән эш | яңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Познавательные УУД** (танып-белү) төшенчәләрне билгеләү,нәтиҗәләрне чыгару;<br>- сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачыклау,<br>- логик фикерләү чылбырын төзү, | Фронталь тикшерү | 14.10 | 14.10 |
| 14 | Тартык [н], авазлары һәм Н,н хәрефләре. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | саңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә | **Личностные УУД(** шәхес буларак) социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү(оценивание усваиваемого содержания, исходя из социальных и личностных ценностей, обеспечивающее личностный моральный выбор | Сораулар буенча әңгәмә | 17.0 | 17.0 |
| 15 | Тартык [л] авазы һәм Л,л хәрефләре. | 1 | катнаш | кушылмалар схемасы белән эш | Яңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив)<br>Планлаштыру<br>Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | Көндәлек тикшерү | 21.10 | 21.10 |
| 16 | Тартык[м] авазы,М,м хәрефләре. | 1 | яңа материалны өйрәнү | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | яңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив)<br>Сораулар куелышы<br>Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек | Сораулар буенча әңгәмә | 24.10 | 24.10 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Тартык [р] авазы һәм Р, р хәрефләре. | 1 | катнаш | табышмаклар һәм Р.Миңнулинның "Хәрефләр бәйрәме" китабы белән эш | авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Иптәшеңенең үз-үзен тотышы белән идарә итү,,фикерне әйтә белү | Фронталь тикшерү | 28.10 | 28.10 |
| 18 | Сузыктан соң килгән тартык **[й]** авазы һәм юл **й** хәрефе. | 1 | катнаш | бәйләнешле сөйләмне үстерү өчен тематик картиналар белән эш | | | Көндәлек тикшерү | 7.11 | 7.11 |
| 19 | Тартык **[ң]** авазы һәм ң хәрефе. | 1 | яңа материалны өйрәнү | кушылмалар схемасы белән эш | яңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Познавательные УУД** (танып-белү) Гомуми уку (общеучебные)<br>- танып-белү максатын билгеләү;<br>-кирәкле информация туплау;<br>- билге-символлар<br>- модельләштерү<br>төшенчәләрне билгеләү,нәтиҗәләрне чыгару;<br>- сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачыклау,<br>- логик фикерләү чылбырын төзү, | | 11.11 | 11.11 |
| 20 | Сузык Я, я хәрефләре. Ку-шылма-ларда я хәрефе. | 1 | катнаш | Басма һәм язма хәрефләре белән эш булган рәсемле алфавит белән эш | кушылмалардан сүзләр төзергә һәм төзелгән сүзләрне кычкырып укырга | | Көндәлек тикшерү | 14.11 | 14.11 |
| 21 | Сузык Ю, ю хәрефләре. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрдә ю хәрефе. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | кисмә хәрефләрдән һәм кисмә кушылмалардан сүзләр төзергәһәм төзелгән сүзләрне кычкырып укырга; | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге<br>Прогнозлау(алдан фаразлау | Көндәлек тикшерү | 18.11 | 18.11 |
| 22 | Сузык Е, **е** хәрефләренең (йы) авазларын белдерү. | 1 | катнаш | бәйләнешле сөйләмне үстерү өчен тематик картиналар белән эш | кисмә хәрефләрдән һәм кисмә кушылмалардан сүзләр төзи белергә | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Контроль<br>Эшчәнлек ысулы, аның нәтиҗәсе һәм бирелгән үрнәк белән тайпылышлар,үзгәлекләрне табу максатыннан | Әңгәмә | 21.11 | 21.11 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | чыгып чагыштыру формасы рәвешендә башкару<br>Коррекцияләү | | | |
| 23 | Тартык **[д]** авазы һәм Д, **д х**әрефләре. | 1 | яңа материалны өйрәнү | Басма һәм язма хәрефләре булган рәсемле алфавит белән эш | Яңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә<br><br>кушылмалардан сүзләр төзергә һәм төзелгән сүзләрне кычкырып укырга | **Личностные УУД(** шәхес буларак) социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү(оценивание усваиваемого содержания, исходя из социальных и личностных ценностей, обеспечивающее личностный моральный выбор | Көндәлек тикшерү | 25.11 | 25.11 |
| 24 | Тартык **[т]** авазы һәм Т,т **х**әреф-ләре.“Төлке һәм торна” әкияте. [д],[т] | 1 | катнаш | кушылмалар схемасы белән эш | | | Фронталь тикшерү | 28.11 | 28.11 |
| 25 | Тартык [з] авазы һәм З,з хәрефләре. “Без”. | 1 | катнаш | кушылмалар схемасы белән эш | - Сүзләрне , кыска һәм гади җөмләләрне укырга | **Личностные УУД(** шәхес буларак) социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү(оценивание усваиваемого содержания, исходя из социальных и личностных ценностей, обеспечивающее личностный моральный выбор | Көндәлек тикшерү | 2.12 | 2.12 |
| 26 | Тартык **[с]** авазы һәм С,с хәрефләре. Дусларым. | 1 | катнаш | Басма һәм язма хәрефләре булган рәсемле алфавит белән эш | Тартык**[с]** авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ;<br><br>саңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Сораулар куелышы<br>Информация табуда һәм туплауда инициативалы бердәмлек<br>**Познавательные УУД** (танып-белү) Гомуми уку (общеучебные)<br>- танып-белү максатын билгеләү;<br>-кирәкле информация туплау;<br>- билге-символлар<br>- модельләштерү | Сораулар буенча әңгәмә | 5.12 | 5.12 |
| 27 | Тартык [гъ],[г]авазлары һәм Г, г хәрефләре Чәчәк үстерү. | 1 | катнаш | кушылмалар схемасы белән эш | | | Фронталь тикшерү | 9.12 | 9.12 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28 | Тартык **[к]** авазы һәм<br>К, к хәрефләре.<br>Туган ягым.<br>[к],г] | 1 | катнаш | бәйләнешле сөйләмне устерү өчен тематик картиналар белән эш<br>класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | саңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә ; | **Познавательные УУД** (танып-белү) Логик<br>- билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>- җитмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау;<br>- чагыштыру,объектларны классларга бүлү, серияләү өчен критерийлар сайлау;<br>төшенчәләрне билгеләү,нәтиҗәләрне чыгару;<br>- сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен ачыклау,<br>- логик фикерләү чылбырын төзү, | Фронталь тикшерү | 12.12 | 12.12 |
| 29 | Ирен-ирен (w)һәм ирен-теш (в) авазлары, В,в хәрефләре. | 1 | яңа материалны өйрәнү | кушылмалар схемасы белән эш | кушылмалардан сүзләр төзергә һәм төзелгән сүзләрне кычкырып укырга | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Максатка ышану (Целеполагание)<br>Укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү<br>Планлаштыру<br>Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге<br>Прогнозлау(алдан фаразлау) | Көндәлек тикшерү | 16.12 | 16.12 |
| 30 | Ирен-ирен (w) (в) авазлары, В,в хәрефләре.<br>Авылда. | 1 | катнаш | бәйләнешле сөйләмне үстерү өчен тематик картиналар | | | Көндәлек тикшерү | 19.12 | 19.12 |
| 31 | Тартык **[ф]** авазы һәм Ф,ф хәрефләре.<br>Уфа-Казан. | 1 | катнаш | абак, сузыклар таблицасы | кечкенә текстларны аңлап , әдәби дөрес һәм салмак итеп , сүзләп кычкырып укырга | **Личностные УУД(** шәхес буларак) социаль һәм шәхси бәялəрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | Көндәлек тикшерү | 23.12 | 23.12 |
| 32 | Тартык **[б]** авазы һәм Б,б хәрефләре.<br>Болында. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр | кушылмалардан сүзләр төзергә һәм төзелгән сүзләрне кычкырып укырга | **Познавательные УУД** (танып-белү) Проблеманы кую һәм аны чишү<br>- проблеманың әйтелеше яки бирелеше;<br>-эзләнүле һәм иҗади характердагы проблемаларны чишү юлларын мөстәкыйль табу. | Әңгәмә | 26.12 | 26.12 |
| 33 | Тартык **[п]** авазы һәм П,п хәрефләре.<br>Песнәкләр. | 1 | катнаш | | Сүзләрне , кыска һәм гади җөмләләрне укырга | **Познавательные УУД** (танып-белү) Логик<br>- билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>- җитмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау;<br>- чагыштыру,объектларны классларга бүлү, | Көндәлек тикшерү | 13.01 | 13.01 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | серияләү өчен критерийлар сайлау; | | | |
| 34 | Тартык **[ж]** авазы һәм Ж, ж хәрефләре. Җылы якларда яшәүче хайваннар. | 1 | катнаш | | саңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп карап аера белергә | **Познавательные УУД** (танып-белү) Проблеманы кую һәм аны чишү<br>- проблеманың әйтелеше яки бирелеше;<br>-эзләнүле һәм иҗади характердагы проблемаларны чишү юлларын мөстәкыйль табу. | Фронталь тикшерү | 16.01 | 16.01 |
| 35 | Тартык **[ш]** авазы һәм Ш, ш хәрефләре. Ташбака белән куян. | 1 | катнаш | абак, хәрефләр таблицасы белән эш | | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Максатка ышану (Целеполагание)<br>Укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү<br>Планлаштыру | Көндәлек тикшерү | 20.01 | 20.01 |
| 36 | Тартык [җ] һәм Җ, җ хәрефләре Җиләк җыю. | 1 | катнаш | бәйләнешле сөйләмне устерү өчен тематик картиналар белән эш | кушылмалардан сүзләр төзергә һәм төзелгән сүзләрне кычкырып укырга | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив)<br>Тикшерү, коррекцияләү, иптәшеңнең эшчәнлеген бәяләү,үз фикереңне тулы әйтә белү | Сораулар буенча әңгәмә | 23.01 | 23.01 |
| 37 | Тартык **[ч]** авазы, Ч,**ч** хәрефләре. Йорт кошлары. Берлектә көч. | 1 | катнаш | бәйләнешле белән эш сөйләмне үстерү өчен тематик картиналар белән эш | кечкенә текстларны аңлап , әдәби дөрес һәм салмак итеп , сүзләп кычкырып укырга | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив)<br>Тикшерү, коррекцияләү, иптәшеңнең эшчәнлеген бәяләү,үз фикереңне тулы әйтә белү | Фронталь тикшерү | 27.01 | 27.01 |
| 38 | Тартык **[х]** авазы, Х,х хәрефләре. Хәзинә. | 1 | катнаш | Басма һәм язма хәрефләре булган рәсемле алфавит белән эш | Сүзләрне , кыска һәм гади җөмләләрне укырга | **Личностные УУД(** шәхес буларак) Үзбилгеләмә(самоопределение)<br>Укуның дәлилләре(мотивация учения)<br>Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности личности). | Фронталь тикшерү | 30.01 | 30.01 |
| 39 | Тартык **[һ]** авазы һәм Һ,һ хәрефләре Шаулама! [х],[һ] | 1 | катнаш | абак, тартыклар таблицасы белән эш | кушылмалардан сүзләр төзергә һәм төзелгән сүзләрне кычкырып укырга | **Личностные УУД(** шәхес буларак) социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | Көндәлек тикшерү | 3.02 | 3.02 |

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 40 | Сузык Ё, **ё** хәрефләре. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | кечкенә текстларны аңлап , әдәби дөрес һәм салмак итеп , сүзләп кычкырып укырга | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Планлаштыру Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | Көндәлек тикшерү | 6.02 | 6.02 |
| 41 | Тартык (щ) авазы , Щ, щ хәрефләре. Борщ. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | кечкенә текстларны аңлап , әдәби дөрес һәм салмак итеп , сүзләп кычкырып укырга | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Максатка ышану (Целеполагание) Укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү Планлаштыру | Көндәлек тикшерү | 10.02 | 10.02 |
| 42 | Тартык [ц] һәм Ц,ц хәрефләре Цирк. | 1 | катнаш | класс өчен һәм индивидуаль кисмә хәрефләр белән эш | кечкенә текстларны аңлап , әдәби дөрес һәм салмак итеп , сүзләп кычкырып укырга | **Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Планлаштыру Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | Көндәлек тикшерү | 20.02 | 20.02 |
| 43 | ь,ъ билгеләре. Ныгыту.Уку тизлекләре,аңлап укуларын тикшерү. | 1 | катнаш | | | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Максатка ышану (Целеполагание) Укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү Планлаштыру | Көндәлек тикшерү | 24.02 | 24.02 |
| 44 | Алфавит. Шигырьләр. | 1 | катнаш | Алфавитны хәреф исемнәрен дөрес әйтеп уку | "Туган тел".Г.Тукай."Туган җир" Р.Бәшәр. "Телевизор баш булды" Ш галиев. | **Личностные УУД(** шәхес буларак) Үзбилгеләм ә(самоопределение) Укуның дәлилләре(мотивация учения) Шәхеснең гражданлык нигезләре формалашуы (формирование основ гражданской идентичности личности). | Көндәлек тикшерү | 27.02 | 27.02 |

**Әдәби уку( 22 сәг.)**

| № | Дәреснең темасы<br>Дәрестә укылачак әсәр | Дәрес тибы | Укыту эшчәнлеге төрләре | Планлаштырылган материалны үзләштерү нәтиҗәләре | | Контроль төре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Көтелгән нәтиҗәләр | Күпкырлы уку эшчәнлеге(УУД) | | План | факт |
| 45 | **1.Сәяхәткә чыгу.-4 сәг.**<br><br>**Сәяхәт башы.**<br>**Булган,ди ,бер Саескан.** | Яңа материалны өйрәтү | әңгәмә, укучылар һәм укытучы чыгышы, шигырь өстендә эш, сорауларга җавап. | Йөгерек һәм сәнгатьле итеп шигырь уку, бәйләнешле итеп үз фикерен әйтә алу | **Личностные УУД(** шәхес буларак) әхлакый-этик бәяләү<br>**Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Планлаштыру Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | Фронталь, индиви-дуаль | 3.03 | 3.03 |
| 46 | Борын-борын заманда...<br>Аптыраткыч – йөдәткеч әкиятләр законы. | Яңа материалны өйрәтү | Табышмакларны укып, мәгънәләренә төшенү. | Йөгерек һәм сәнгатьле итеп шигырь уку, бәйләнешле итеп үз фикерен әйтә алу, эти-әнигә шәфкатьле булу | **Познавательные УУД** (танып-белү)<br>Гомуми уку (общеучебные)<br>- танып-белү максатын билгеләү;<br>-кирәкле информация туплау;<br>- билге-символлар<br>- модельләштерү | | 5.03 | 5.03 |
| 47 | Бирәм,бирәм...<br>Табышмаклар. | | | | | | 10.03 | 10.03 |
| 48 | Санамышлар. | Белемнәрне ныгыту | Санамышларны укып, мәгънәләренә төшенү. | | **Регулятивные УУД** (көйләгеч) Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге<br>Прогнозлау(алдан фаразлау) | Фронталь, индиви-дуаль | 12.03 | 12.03 |
| 49 | **2.“Кайтаваз”мә-гарәсе.-2 сәг.**<br>М.Галиев.<br>Кайтаваз. | Яңа материалны өйрәтү | Дуслык, юмартлык турында әңгәмә, хикәяләрне уку, сорауларга җавап бирү, дуслар турында сөйләү. | Йөгерек һәм сәнгатьле итеп һәм аңлап уку, сорауларга дөрес итеп җавап бирү | **Личностные УУД(** шәхес буларак) әхлакый-этик бәяләү<br>**Коммуникативные УУД** (коммуникатив) Планлаштыру Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп | Фронталь, индиви-дуаль | 17.03 | 17.03 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | | | |
| 50 | Р.Газизов.Беләсезме...<br>Р.Корбан. Көчек.Яңгыр яуганда. | Белемнәрне ныгыту | | | | | 19.03 | 19.03 |
| | **<u>3.Аю өне янында.-2 сәг.</u>**<br>Х.Халиков.Бии белмәгән аю. Аю һәм өч кыз.<br>(Татар халык әкияте) | Яңа материалны өйрәтү | Эчтән уку, чылбырлап уку, сайлап уку, рольләргә бүлеп уку.<br>Эчтәлеген сөйләргә өйрәнү. | Укылган текстка карата куелган сорауларга җавап бирү, әсәрне гади итеп бәяли белү, рәсемгә карап телдән хикәя төзү | **Познавательные УУД** (танып-белү)<br>Логик<br>- билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>- җитмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау;<br>- чагыштыру,объектларны классларга бүлү, серияләү өчен критерийлар сайлау; | Уку тизлеген һәм аңлап укуын тикшерү | 2.04 | 2.04 |
| 51 | Аю һәм өч кыз.<br>(Татар халык әкияте) | | | | | | 7.04 | 7.04 |
| 52 | **<u>4.Чәчәкле аланда.-2 сәг.</u>**<br>Р.Бәшар.Авылга кайту. | Яңа материалны өйрәтү | Үзеңнең гаилә кешеләрең турында матур итеп сөйләү. | Җөмләләр арасында пауза ясап дөрес итеп уку, текстны дөрес итеп уку, әсәрне гади итеп бәяли белү. | **Познавательные УУД** (танып-белү)<br>Логик<br>- билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>- җитмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау;<br>- чагыштыру,объектларны классларга бүлү, серияләү өчен критерийлар сайлау; | Фронталь, индиви-дуаль | 9.04 | 9.04 |
| 53 | Э.Шәрифуллина.Бәйрәм ашы – кара-каршы. | Яңа материалны өйрәтү | Табигать турында әңгәмә, дәрестә укылачак әсәрләр белән танышу, сорауларга җавап бирү, сүзлек өстендә эш,эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | Укылган текстка карата куелган сорауларга җавап бирү, әсәрне гади итеп бәяли белү, рәсемгә карап телдән хикәя төзү<br>Җөмләләр арасында пауза ясап дөрес итеп уку, | **Регулятивные УУД** (көйләгеч)<br>Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге<br>Прогнозлау(алдан фаразлау<br>**Личностные УУД(** шәхес буларак)<br>әхлакый-этик бәяләү<br>**Коммуникативные УУД** (коммуни-катив) Планлаштыру<br>Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | Уку тизлеген һәм аңлап укуын тикшерү. | 14.04 | 14.04 |
| 54 | **<u>5.Урман мәктәбендә.-3 сәг.</u>**<br>Х.Халиков.<br>Р.Миңнуллин.Үзебез генә калгач. | | | | | | 16.04 | 16.04 |
| 55 | | Яңа | Кереш әңгәмә, | | | Фронталь, | 21.04 | 21.04 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Поэзиядә юмор хисе.<br>Ш.Галиев.Шауламагыз,эти йоклый. | материалны өйрәтү | дәрестә укылачак әсәрләр белән танышу, сорауларга җавап бирү, сүзлек өстендә эш,эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | текстны дөрес итеп уку, әсәрне гади итеп бәяли белү. | | индиви-дуаль | | |
| 56 | Поэзиядә юмор хисе.<br>Өтерне кайда куярга? | Яңа материалны өйрәтү | Кереш әңгәмә, хезмәт, уку турында мәкальләр белән танышу, мәгънәләрен аңлату, эчтән, кычкырып, сайлап уку. | Йөгерек һәм сәнгатьле итеп һәм аңлап уку, сорауларга дөрес итеп җавап бирү | **Личностные УУД(** шәхес буларак) Мәгънә төзелеше (Смыслообразования)<br>«минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», һәм шул сораугa җавап бирә белү. социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | Фронталь, индиви-дуаль | 23.04 | 23.04 |
| 57 | **6.<u>Шүрәледә кунакта.-</u>**<br>**<u>3 сәг.</u>**<br>Класстан тыш уку. Әкияттә кунакта.<br>Р.Кутуй.Төнге әкият. | Белемнәрне ныгыту дәресе | Татар халык әкиятләре турында кереш әңгәмә, сорауларга җавап бирү, слайдлар карау, магнитафон язмасында әкиятләрдән өзекләр тыңлау, әкият уку. | Йөгерек һәм сәнгатьле итеп һәм аңлап уку, сорауларга дөрес итеп җавап бирү | **Познавательные УУД** (танып-белү) Логик<br>- билгеләрне табу максатыннан чыгып, анализлау<br>- җитмәгән компонентларны тулыландырып,синтезлау;<br>- чагыштыру,объектларны классларга бүлү, серияләү өчен критерийлар сайлау; | Фронталь, индиви-дуаль | 28.04 | 28.04 |
| 58 | Р.Хисмәтуллин.<br>Хәерле иртә! | Яңа материалны өйрәтү | Шагыйрь белән танышу, укыту сөйләме, сорауларга җавап бирү, сүзлек өстендә эш, эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | Рәсемгә карап әкиятнең эчтәлеген сөйләү, Г.Тукай турында кыскача әйтә алу, шигырьләрнең исемнәрен атау. | **Регулятивные УУД** (көйләгеч) Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге<br>Прогнозлау(алдан фаразлау | Фронталь, индиви-дуаль | 30.04 | 30.04 |
| 59 | Р.Вәлиева.Кыңгырау чәчәк. | | | | | | 5.05 | 5.05 |
| 60 | **<u>7.Китап рәссамы күргәз-мәсендә.-6 сәг.</u>**<br>Х.Халиков.Көймәче мәче. | Яңа материалны өйрәтү | Шагыйрь белән танышу, укыту сөйләме, сорауларга җавап бирү, сүзлек | Укылган әсәрнең исемен аңлату.<br>М.гафуриның | **Личностные УУД(** шәхес буларак) әхлакый-этик бәяләү<br>**Коммуникативные УУД** (коммуни-катив) Планлаштыру | Уку тизлеген һәм аңлап укуын тикшерү | 7.05 | 7.05 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | өстендә эш, эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | дәрестә укыган әсәрләренең исемнәрен атау | Максатны,,катнашучыларның функцияләрен,бергәләп эшчәнлекнең алымнарын билгеләү | | | |
| 61 | М.Әгъләмов.Килсен безгә әкият. | Яңа материалны өйрәтү | Язучы белән танышу, укыту сөйләме, сорауларга җавап бирү, үрнәк уку, сүзлек өстендә эш, эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | Йөгерек һәм сәнгатьле итеп һәм аңлап уку, сорауларга дөрес итеп җавап бирү, язучыны тану, укылган хикәянең исемен әйтә алу. | **Личностные УУД(** шәхес буларак) Мәгънә төзелеше (Смыслообразования) «минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», һәм шул сораугa җавап бирә белү. социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | Фронталь, индиви-дуаль | 12.05. | 12.05. |
| 62 | Х.Туфан.Юкмыш бабай малае. | | | | | | 14.05 | 14.05 |
| 63 | Буталмыш әкият. | Яңа материалны өйрәтү | Укыту сөйләме, сорауларга җавап бирү, сүзлек өстендә эш, эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | Йөгерек һәм сәнгатьле итеп һәм аңлап уку, сорауларга дөрес итеп җавап бирү, шагыйрьне тану, укылган шигырьләрнең исемен әйтә алу | **Регулятивные УУД (**көйләгеч) Соңгы нәтиҗәләрне исәпкә алып, максатларның эзлеклелеген билгеләү.план төзү һәм эшнең эзлеклелеге Прогнозлау(алдан фаразлау | Фронталь, индиви-дуаль | 19.05 | }19.05 |
| 64 | Дөньяда булмаган әкият. | | Татар халык иҗаты белән танышу, укыту сөйләме, сорауларга җавап бирү, сүзлек өстендә эш, эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | | **Познавательные УУД** (танып-белү) Гомуми уку (общеучебные)<br>- танып-белү максатын билгеләү;<br>-кирәкле информация туплау;<br>- билге-символлар<br>- модельләштерү | Фронталь, индиви-дуаль | 19.05 | |
| 65 | Р.Фәйзуллин.Табигать Кочагында. | | Шагыйрь белән танышу, укыту сөйләме, сорауларга җавап бирү, сүзлек өстендә эш, эчтән һәм чылбыр тәртибендә уку. | | **Личностные УУД(** шәхес буларак) Мәгънә төзелеше (Смыслообразования) «минем өчен уку нинди мәгънәгә ия», һәм шул сораугa җавап бирә белү. социаль һәм шәхси бәяләрдән чыгып,шәхеснең мораль сайланышында үзләштерү эчтәлеген бәяләү | | 21.05 | }21.05 |
| 66 | Китап рәссамы күргәзмәсендә. Еллык йомгак. | | | | | | 21.05 | |

**Мәгълүмат  һәм белем бирү чыганаклары**

1. Р.Г.Вәлитова, С.Г. Вагыйзов “Әлифба” белән ничек эшләргә.  Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2012
2. Р.Г.Вәлитова, С.Г. Вагыйзов “Башлангыч мәктәпләрдә татар телен укыту методикасы”. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009
3. Урта мәктәп программалары. Башлангыч сыйныфлар. Казан, Татарстан нәшрияты, 2010.
4. “Мәгариф”, “Ачык дәрес” Һәм башка методик газета – журналлар.

7. Язучыларның балалар өчен китаплары.

▪ "Башлангыч гомуми белем бирү программалары”(Татар телендә гомуми белем бирү мәктәбе өчен.1-4сыйныфлар,2010 ел)

▪“Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек",(Әлифба), 2011 ел ,авторлары:

И.Х.Мияссарова,Ф.Ш.Гарифуллина,Р.Р.Шәмсетдинова;

▪“Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек",(Әдәби уку), 2011 ел,авторлары:Г.М.Сафиуллина,М.Я.Гарифуллина,Ә.Г.Мөхәммәтҗанова,Ф.Ф.Хәсәнова